ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 426

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«20» 07 2015 ел.

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында**

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 20.1 статьялары, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17.1 статьялары нигезендә, 2014 елның 22 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 431-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясын, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге “Керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә рәвешен раслау турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 460 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында” ПУ-702 номерлы Указын исәпкә алып, **б о е р ы к б и р ә м :**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба – ТР ДТИ) аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Вазифалар исемлеге) расларга.

2. Вазифалар исемлегенә алар буенча вазифаи йөкләмәләрне үтәү түбәндәгеләрне күз алдында тотучы вазифалар кертелүен билгеләргә:

даими, вакытлыча яки хакимият вәкиле функцияләренең махсус вәкаләтләре яисә оештыру-боеру яки административ-хуҗалык функцияләре нигезендә башкару;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

контрольлек чаралары башкару;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын гамәлгә ашыру;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлеп бирү.

3. Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләгән затларга, дәүләт гражданлык хезмәтеннән куылганда, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләр, бурычлар турында аңлатырга.

4. 2013 елның 31 октябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында” 149 номерлы, 2014 елның 9 декабрендәге “2013 елның 31 октябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында”гы 149 номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында” 184 номерлы боерыкларны көчен югалткан дип танырга.

5. Кадрлар бүлеге башлыгына (И.Н. Никитина) Исемлеккә кертелгән вазифаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясе
башлыгының 2015 елның
20 07
№426 боерыгы белән
расланды____

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге

1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы;
2. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы урынбасары;
3. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – хокукый идарә башлыгы;
4. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – зональ торак инспекциясе башлыгы;
5. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы;
6. Казан шәһәре торак инспекциясе башлыгы урынбасары;
7. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы;
8. Үзәк инспекторлык бүлеге башлыгы урынбасары;
9. Чаллы зонасы торак инспекциясе башлыгы урынбасары;
10. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
11. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
12. Үзәк инспекторлык бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
13. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлеге башлыгы;
14. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
15. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
16. Торак фондын капиталь ремонтлауны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
17. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булуын тикшерү бүлеге башлыгы;
18. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булуын тикшерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
19. ТКХ өчен түләүләрнең нигезле булуын тикшерү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

20. Хокукый идарәнең юридик бүлеге башлыгы;
21. Хокукый идарәнең юридик бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
22. Хокукый идарәнең юридик бүлегенең әйдәп баручы консультанты;
23. Хокукый идарәнең юридик бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
24. Хокукый идарәнең административ тәҗрибә бүлеге башлыгы;
25. Хокукый идарәнең административ тәҗрибә бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
26. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы бүлеге башлыгы;
27. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;
28. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге башлыгы;
29. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече;
30. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;
31. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенең 1 разрядлы белгече;
32. Кадрлар бүлеге башлыгы;
33. Кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
34. Кадрлар бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
35. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге башлыгы;
36. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;
37. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
38. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенең 1 разрядлы белгече;
39. Гомуми бүлек башлыгы;
40. Гомуми бүлекнең 1 разрядлы өлкән белгече;
41. Казан шәһәре торак инспекциясе консультанты;
42. Зональ торак инспекциясе консультанты;
43. Казан шәһәре торак инспекциясенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
44. Зональ торак инспекциясенең әйдәп баручы белгече – эксперты;
45. Казан шәһәре торак инспекциясенең 1 разрядлы белгече;
46. Зональ торак инспекциясенең 1 разрядлы белгече.

---